РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

*Решение* *Карар*

2026 елның 18 феврале Чистай шәһәре №6/2

Чистай шәһәр Советының
«Физик затлар мөлкәтенә
салым турында» 2015 елның
10 сентябрендәге 43/1 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 ел, № 425-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 маддәсе, 30.10.2014 ел, № 82-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында», салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып», Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 10 сентябрендәге 43/1 номерлы Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Советы карарына (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2015 елның 26 октябрендәге 2/5 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 28/2 номерлы, 2018 елның 23 декабрендәге 29/1 номерлы, 2024 елның 26 сентябрендәге 34/2 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) карата 2 процент:

- «һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектларына, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган, төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-

коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 2 пунктындагы 5 пунктчасында каралган үзгәрешләр 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләсе буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов